Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Барҗы-Пельга торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**01 ноябрь 2023** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның "01" ноябрендә 13 сәгать 00 минутта уткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Кичкетаң авыл җирлеге" Барҗы-Пельга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан, ирегеннән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан тыш, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юлланган 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану белән килешәсезме:

а) Урам челтәрләрен тышкы яктыртуны ремонтлау (дроссель лампаларын сатып алу һәм алыштыру).

б) халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү (тракторны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү).

в) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу).

г) халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү (рөхсәтсез чүплекләрне бетерү).

д) киртәләр төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (койма өчен материаллар сатып алу).

е) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юллар өчен вак таш сатып алу һәм җәю).

РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 88 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 50 кеше, бу 56,8 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 50 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Барҗы-Пельга торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип таныргa.

2. I төркем инвалидларыннан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ихтыярый затлар) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар), ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, 2024 елда “Кичкетаң авыл җирлеге” территориясенең Барҗы-Пельга авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, киртәләрне төзекләндерү (материаллар сатып алу);

- Урам челтәрләрен тышкы яктыртуны ремонтлау (дроссель лампаларын сатып алу һәм алыштыру).

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек башлыгы И.Н. Җиһангәрәев